РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
20.06.2019

**КАРАР**
№ 488

**Тәтеш муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген раслау турында**

Тәтеш муниципаль районы Уставы нигезендә, федераль һәм төбәк законнарында беркетелгән җирле үзидарә органнарының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты  яңа редакциядә **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Тәтеш муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

2. Муниципаль контроленең тиешле төрен үткәрүгә вәкаләтле Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләре, Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген билгеләргә (2 нче кушымта).

3. Муниципаль контрольне үткәрүгә вәкаләтле Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләренә, Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

- муниципаль контрольне гамәлгә ашыра торган административ регламентларның проектларын эшләргә һәм раслауга тапшырырга;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының  “Тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү хакында”гы  2011 елның 13 августындагы 676 карары белән билгеләнгән

тәртиптә һәм вакытта статистик мәгълүматлар, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында докладлар проектларын Тәтеш районы башкарма комитетының социаль-икътисадый һәм территориаль үсеш бүлегенә тапшырырга.

4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм мондый контрольнең нәтиҗәлелеге турында докладларны гомумиләштерү, “Мониторинг” мәгълүмат системасына мәгълүмат кертү өчен җаваплы итеп Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының социаль-икътисадый һәм территориаль үсеш бүлеген билгеләргә.

5. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 13 мартындагы 171 карарын үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**